ГЛАВА
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

20.11.2020 Сарсак-Омга ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Омга торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Омга авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Омга авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Омга торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 04 декабрендә 14 сәг 00 мин билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Омга торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2020 елның 04 декабрендә 16 сәг 00 мин билгеләргә.

Халыклар исемлеген территориаль билге буенча бүләргә:
-1 этап: Сарсак-Омга авылының Ворошилов, Береговая, К. Маркс, 1 - 56 адресы буенча яшәүчеләр.
-2 этап: Сарсак-Омга авылының Ленин, Логовая, Красноармейская, Яшләр, Киров мәйданы, К. Маркс, 59-76 адресы буенча яшәүчеләр.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Омга

авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Омга торак торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Сарсак-Омга авылында юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю (юлга торбалар салу);
2. Халыкны су белән тәэмин итү өчен су башнясын карап тоту һәм төзекләндерү (павильоннар урнаштыру һәм скважиналар өчен култыксалар ясау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
3.Зиратта чүп җыю мәйданчыгы урнаштыру һәм контейнер сатып алу;
4. Юлларга хезмәт күрсәтү - авыл җирлеге чикләрендә урамнарны кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
5. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор (бульдозер) өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу;
6. Массакүләм ял итү урыннарын оештыру (сәхнә һәм навес урнаштыру өчен төзелеш материалын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
7. Сарсак-Омга авылында кешеләрнең иминлегенә һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләр кистерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы Сарсак-Омга ав., Киров мәйданы, 15 йорт, авыл мәдәният йортында уздырырга.
5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Омга авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Омга авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Т.С. НИКОЛАЕВА

Совет Сарсак-Омгинского сельского поселения
Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002565
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ